ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 84 статьясы, «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 69 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына ярты елга бер тапкыр сайлау округындагы эше турындагы мәгълүматны кушымта итеп бирелгән форма нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына тапшырырга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (II өлеш);

2) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 14 апрелендәге 3473-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 4);

3) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 14 ноябрендәге 133-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2019, № 11);

4) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 2 июнендәге 1975-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарының 3 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2023, № 5 – 6).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Мавринага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 22 ноябре
№ 19-VII ДСП

2024 елның 22 ноябрендәге
19-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

20___ елның ___ яртыеллыгы өчен
_______________ сайлау округындагы эше хакында
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты
МӘГЪЛҮМАТЫ

1. Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары
утырышлары эшендә катнашу

| № т/б | Вәкиллекле орган исеме | Уздыру урыны һәм датасы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

2. Сайлаучылар белән очрашулар, округтагы башка чаралар (җыелышлар,
митинглар, пикетлар, конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» һ.б.)

| № т/б | Чара | Уздыру урыны һәм датасы | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

3. Гражданнарны шәхси кабул итү

| № т/б | Кабул итү датасы | Кабул итү урыны | Кабул ителгән гражданнар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

4. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау
4.1. Мөрәҗәгатьләр кергән элемтә төрләре буенча мөрәҗәгатьләр саны

| № т/б | Мөрәҗәгатьләр кергән элемтә төрләре | Мөрәҗәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Интернет аша кабул итү | |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Электрон почта | |
| 3. | Россия почтасы | |
| 4. | Шәхси кабул итү | |
| 5. | Кулга | |
| 6. | Башка элемтә төрләре | |
| | Барлыгы | |

4.2. Тематик бүлекләр буенча мөрәҗәгатьләр саны

| № т/б | Тематик бүлекләр | Мөрәҗәгатьләр саны | Төп мәсьәләләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге: | | |
| а) | гражданнарның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы адресына тәкъдимнәре (шул исәптән законнарны камилләштерү буенча) | | |
| б) | гражданнарның Татарстан Республикасы Рәисе, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре адресына тәкъдимнәре | | |
| в) | вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр | | |
| г) | гражданнарның башка тәкъдимнәре | | |
| 2. | Икътисад, сәнәгать | | |
| 3. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | | |
| 4. | Транспорт һәм юл хуҗалыгы | | |
| 5. | Төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | | |
| 6. | Коммуналь хезмәт күрсәтүләр | | |
| 7. | Экология һәм табигать ресурслары | | |
| 8. | Мәгариф, фән һәм мәдәният | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Сәламәтлек саклау | | |
| 10. | Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү | | |
| 11. | Социаль яклау | | |
| 12. | Законлылыкны һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итү | | |
| 13. | Башка мәсьәләләр | | |
| | Барлыгы | | |

4.3. Ташламалы категорияләр буенча мөрәҗәгать итүчеләр саны

| № т/б | Ташламалы категорияләр | Мөрәҗәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары | |
| 2. | Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары | |
| 3. | Хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары | |
| 4. | Тыл хезмәтчәннәре, хезмәт ветераннары, пенсионерлар | |
| 5. | Инвалидлар, инвалид балалар | |
| 6. | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар | |
| 7. | Хәрби хәрәкәттә катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаиләләре | |
| 8. | Күпбалалы гаиләләр | |
| 9. | Яшь гаиләләр | |
| 10. | Эшсезләр һәм вакытлыча эшләмәүчеләр | |
| | Барлыгы | |

4.4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре

| № т/б | Мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре | Мөрәҗәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Уңай хәл ителгән | |

| | | |
|---|---|---|
| 2. | Аңлатмалар бирелгән, шул исәптән нигезле кире кагулар | |
| 3. | Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган тиешле органнарга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелгән | |

4.5. Уңай хәл ителгән мәсьәләләрнең мисаллары

| № т/б | Уңай хәл ителгән мәсьәлә |
|---|---|
| 1 | 2 |
| | |

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты ______________ ______________________________
(имза) (инициаллар, фамилия)

Дата